РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 18 » декабрь 2017ел. Буа шәһәре № 146/п

Буа муниципаль районының тормыш
дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне
легальләштерү буенча ведомствоара
комиссиясенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Буа муниципаль районының тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгының 2008 елның 29 сентябрендәге 88 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

-3 пунктның 7 абзацын төшереп калдырырга;

- 3 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«дәүләт (муниципаль) чыгымнарын оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;»;

- 3 пунктның 15 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хуҗалык итүче субъектларның икътисадый һәм хуҗалык эшчәнлегенең аерым фактлары буенча законда билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрне башлап җибәрү максатларында хокук саклау органнарына мөрәҗәгатьләр җибәрү;»;

- 4 пунктның 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хуҗалык итүче субъектларның икътисадый һәм хуҗалык эшчәнлегенең аерым фактлары буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрне башлап җибәрү максатларында хокук саклау органнарына мөрәҗәгатьләр җибәрергә, шулай ук дәүләт (муниципаль) контроле кысаларында тикшерүләрне башлап җибәрү максатында вәкаләтле органнарга мөрәҗәгать итәргә.;»;

- 11 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара, Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп тора.»;

- 12 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Комиссиянең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары барлык җирле үзидарә органнары, министрлыклар һәм ведомстволарның территориаль органнары, учреждениеләр, шулай ук, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятиеләр һәм башка оешмалар тарафыннан башкару өчен мәҗбүри.».

2. Әлеге карар имза салынган вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру (http://buinsk.tatarstan.ru) юлы белән бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары Е.А. Семагинга йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы М.А. Җәббаров